ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04 сентябрь 2015 ел № 4937

Үтәлү срогы 2015 елда тәмамлана торган контрактларда каралган контрактны үтәү срогын, һәм (яки) контрактның бәясен, һәм (яки) товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлеге бәясен, һәм (яки) товар санын, эш, хезмәт күрсәтү күләмен яклар килешүе буенча үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында

«Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законның 95 маддәсендәге 1.1 бүлеге нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Үтәлү срогы 2015 елда тәмамлана торган контрактларда каралган контрактны үтәү срогын, һәм (яки) контрактның бәясен, һәм (яки) товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлеге бәясен, һәм (яки) товар санын, эш, хезмәт күрсәтү күләмен яклар килешүе буенча үзгәртү кагыйдәләрен кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы Ә.А. Галиәкбәровага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2015 елның 4 сентябрендәге
4937 нче карарына
кушымта

Үтәлү срогы 2015 елда тәмамлана торган контрактларда каралган контрактны үтәү срогын, һәм (яки) контрактның бәясен, һәм (яки) товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлеге бәясен, һәм (яки) товар санын, эш, хезмәт күрсәтү күләмен яклар килешүе буенча үзгәртү кагыйдәләре

1. Әлеге үтәлү срогы 2015 елда тәмамлана торган контрактларда каралган контрактны үтәү срогын, һәм (яки) контрактның бәясен, һәм (яки) товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлеге бәясен, һәм (яки) товар санын, эш, хезмәт күрсәтү күләмен яклар килешүе буенча үзгәртү кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) үтәлү срогы 2015 елда тәмамлана торган контрактларда (заказчыларның ихтыяҗлары өчен товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә бюджет һәм автономияле учреждениеләрнең «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр төзелгән гражданлык-хокукый килешүләрен, муниципаль контрактларны кертеп) (алга таба – контрактлар) каралган контрактны үтәү срогын, һәм (яки) контрактның бәясен, һәм (яки) товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлеге бәясен, һәм (яки) товар санын, эш, хезмәт күрсәтү күләмен 2015 елда яклар килешүе буенча үзгәртү тәртибен билгели.

2. Әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктында каралган контракт шартларын үзгәртү контрактлар буенча йөкләмәләрне 2015 елда кабул итү һәм (яки) үтәү өчен заказчы тарафыннан җиткерелгән финанс белән тәэмин итү күләме чикләрендә рөхсәт ителә.

3. Әлеге Кагыйдәләр үтәлү срогы 6 айдан артык булган һәм якларга бәйсез вакыйгалар буенча аларның шартларын үзгәртмәү мөмкин булмаган, һәм предметы булып түбәндәгеләр торган контрактларга карата кулланыла:

1) әлеге Кагыйдәләргә кушымтада каралган исемлеккә кертелгән товарларны кайтару, эшләрне башкару, хезмәтләрне күрсәтү. Шулай ук, муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алуларны гамәлгә ашырганда контракт бәясе 1 млн. сумнан артык булырга, һәм сатып алуларда катнашучылар булып бары тик кече эшмәкәрлек субъектлары, социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар торырга мөмкин конкурслар, электрон аукционнар, тәкъдим запрослары үткәрү нәтиҗәләре буенча муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен контракт төзелгән очракта, 5 млн. сумнан артмаска тиеш;

2) төзү, реконструкцияләү, техник яктан яңадан коралландыру сметасына кергән җиһазны сатып алу, һәм (яки) фәнни-методик кулланмадан тыш, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау буенча эшләр үткәрүне кертеп, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, техник яктан яңадан коралландыру.

4. Әлеге Кагыйдәләр аларның валютасы булып Россия сумы торган контрактларга

карата кулланыла.

5. Әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктында каралган контракт шартларын үзгәртү, Россия Федерациясе Гражданнар кодексының 451 маддәсе нигезендә вакыйгаларның мөһим үзгәрүе сәбәпле, контракт шартларын үзгәртмичә аны үтәү мөмкин булмауны дәлилләп, әзерләү өчен, тәэмин итүченең (подрядчының, башкаручының) заказчы адресына язмача рәвештә юлланган мөрәҗәгате нигез булып торган өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә.

Заказчы әлеге Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә контрактка үзгәрешләр кертү турында карар кабул итә. Тәэмин итүченең (подрядчының, башкаручының) әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгате булмаса, заказчы контракт бәясен, товар, башкарыла торган эш, күрсәтелә торган хезмәт бәрәмлеге бәясен арттыру турында карар кабул итүгә хокуксыз.

6. Заказчы контрактка үзгәрешләр кертү турындагы карарны түбәндәгеләрдән чыгып кабул итә:

1) гражданнарның нормаль яшәеше өчен кирәкле товарлар (азык-төлек, ашыгыч, шул исәптән экстрен яки кичектергесез рәвештә ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү, дарулар) кайтару аның предметы булып торган контрактларны беренче чиратта үтәү зарурлыгы;

2) муниципаль программалар, федераль максатчан программалар яисә җирле үзидарә органнарының программа булмаган эшчәнлек юнәлешләре (функцияләре, вәкаләтләре) чараларының, шулай ук капиталь туплауны гамәлгә ашыруга Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетлары акчаларын бирү турында билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән карарларның нәтиҗәләренә ирешү зарурлыгы;

3) контрактка үзгәрешләр кертү турында карар кабул итү датасына, контрактта күздә тотылган һәм фактик үтәлгән йөкләмәләр күләме;

4) 2015 елда контрактлар буенча йөкләмәләр кабул итү һәм (яки) аларны үтәү өчен расланган һәм заказчыга җиткерелгән финанс белән тәэмин итү күләме.

7. Заказчы әлеге Кагыйдәләрнең 5 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән документлар һәм мәгълүмат кергәннән соң 30 көннән артмаган срокта, контрактка үзгәрешләр кертү турында карар кабул итә һәм тәэмин итүчегә (подрядчыга, башкаручыга) кабул ителгән карар турында белдерү кәгазе җибәрә.

8. Контрактка өстәмә килешү әзерләгәндә, заказчы тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән контрактның яңа шартларын килешенә.

9. Әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән контракт шартларын үзгәртүне хисаплау һәм нигезләү контрактка өстәмә килешүнең аерылгысыз өлеше булып торган кушымта белән рәсмиләштерелә.

10. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә төзелгән контрактка өстәмә килешүдә кайтарыла торган товар санын, башкарыла торган эш яки күрсәтелә торган хезмәтләр күләмен арттыру күздә тотылырга мөмкин түгел.

11. Контрактны үтәү срогын үзгәртү 2015 ел чикләрендә якларның килешенүе буенча гамәлгә ашырыла.

12. Контрактның бәясе (муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү һәм техник яктан коралландыру аның предметы булып торган контрактлардан тыш) түбәндәге формула буенча исәпләнгән кыйммәт чикләрендә, якларның килешенүе буенча артырга мөмкин:

$$Ц_{нов} = \left(Ц - С_{п}\right) \times ИКЦ + С_{п},$$

монда:

Ц – контрактның башлангыч бәясе;

$С_{п}$ – заказчы тарафыннан контракт буенча күчерелгән акча суммасы;

ИКЦ – әлеге Кагыйдәләрнең 13 пункты нигезендә билгеләнгән бәяләргә төзәтмә кертү индексы.

13. Контракт бәяләрен үзгәртү өчен Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары белән билгеләнгән индекслар кулланыла.

14. Заказчының товар санын, башкарыла торган эш, күрсәтелә торган хезмәт күләмен киметү турындагы карары әлеге Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә кабул ителергә мөмкин. Шуның белән бергә, әлеге Кагыйдәләрнең 15 пункты нигезендә товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлегенең бәясе артырга мөмкин.

15. Әлеге Кагыйдәләрнең 14 пунктында күрсәтелгән очракта товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлегенең бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнгән кыйммәт чикләрендә билгеләнә:

$$Ц_{ед\ нов} = \left((К - С_{п} / Ц_{ед}) \times Ц_{ед} \times ИКЦ + С_{п}\right) / К,$$

монда:

К – контрактта каралган товар саны, башкарыла торган эш, күрсәтелә торган хезмәт күләме;

$С_{п}$ – заказчы тарафыннан контракт буенча күчерелгән акча суммасы;

$Ц_{ед}$ – контрактта каралган товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлегенең башлангыч бәясе;

ИКЦ – әлеге Кагыйдәләрнең 13 пункты нигезендә билгеләнгән бәяләргә төзәтмә кертү индексы.

16. Әлеге Кагыйдәләрнең 14 пунктында күрсәтелгән очракта, контракт бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнгән кыйммәт чикләрендә, якларның килешенүе буенча үзгәртелергә мөмкин:

$$Ц_{нов} = Ц_{ед\ нов} \times К_{нов},$$

монда:

$Ц_{ед\ нов}$ – әлеге Кагыйдәләрнең 15 пункты нигезендә билгеләнгән товар берәмлегенең, башкарыла торган эш, күрсәтелә торган хезмәт күләменең яңа бәясенең чик кыйммәте;

$К_{нов}$ – киметелгән товар саны, башкарыла торган эш, күрсәтелә торган хезмәтләр күләме.

17. Капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү һәм техник яктан коралландыру, фәнни-методик кулланмадан тыш, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау буенча эшләр үткәрү аның предметы булып торган контрактның бәясен үзгәртү

түбәндәге формула буенча исәпләнгән кыйммәт чикләрендә гамәлгә ашырыла:

$$Ц_{нов} = Ц + Ц_{15} \times \left(ИД_{15Н} - ИД_{15}\right) / ИД_{15} \; ,$$

монда:

Ц – контрактның башлангыч бәясе;

$Ц_{15}$ – 2015 елда контракт шартлары нигезендә түләүләр күләме;

$ИД_{15Н}$ – Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеш прогнозы составында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан хупланган һәм контрактны үзгәрү датасына гамәлдә булган 2015 елгы «Финанслауның барлык чыганаклары хисабына төп капиталга инвестицияләр» прогноз индекс-дефляторы 2014 елга карата процентларда;

$ИД_{15}$ – Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеш прогнозы составында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан хупланган һәм капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү һәм техник яктан коралландыру, фәнни-методик кулланмадан тыш, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау буенча эшләр үткәрү буенча инвестицион проектны тормышка ашыруга Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетыннан бюджет акчалары бүлеп бирү турында норматив хокукый актны кабул итү датасына гамәлдә булган 2015 елгы «Финанслауның барлык чыганаклары хисабына төп капиталга инвестицияләр» прогноз индекс-дефляторы 2014 елга карата процентларда.

18. Капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү һәм техник яктан коралландыру, фәнни-методик кулланмадан тыш, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау буенча эшләр үткәрү аның предметы булып торган контрактның бәясен үзгәрткәндә, заказчы һәм подрядчы белән килешенгән төзелеш кыйммәтенең җыелма смета хисабына кертелергә тиешле чыгымнар күләме Россия Федерациясе законнары нигезендә расланган аерым төр чыгымнарга гамәлдәге смета нормативларыннан артык булырга тиеш түгел.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова

Үтәлү срогы 2015 елда тәмамлана торган контрактларда каралган контрактны үтәү срогын, һәм (яки) контрактның бәясен, һәм (яки) товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлеге бәясен, һәм (яки) товар санын, эш, хезмәт күрсәтү күләмен яклар килешүе буенча үзгәртү кагыйдәләренә кушымта

## Үтәлү срогы 2015 елда тәмамлана торган контрактларда каралган контрактны үтәү срогын, һәм (яки) контрактның бәясен, һәм (яки) товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлеге бәясен, һәм (яки) товар санын, эш, хезмәт күрсәтү күләмен яклар килешүе буенча 2015 елда үзгәртү рөхсәт ителә торган контрактларның предметы булып торган товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр исемлеге

| Товар, эш, хезмәт күрсәтү төркемнәренең исеме | «ОК 034-2014 (КПЕС 2008). Икътисадый эшчәнлек төрләре буенча гомумроссия продукция классификаторы» икътисадый эшчәнлек төрләре буенча гомумроссия продукция классификаторы нигезендәге бүлек |
|---|---|
| Азык-төлек продуктлары | С бүлеге «Эшкәртү производстволары продукциясе» |
| Эчемлекләр | |
| Тукыма һәм тукыма әйберләр | |
| Кием-салым | |
| Кәгазь һәм кәгазь эшләнмәләр | |
| Дарулар һәм медицина максатларында кулланыла торган материаллар | |
| Компьютер, электрон һәм оптик җиһазлар | |
| Мебель | |
| Биналар һәр биналар төзү буенча эшләр | F бүлеге «Корылмалар һәм төзелеш эшләре» |
| Гражданнар төзелеше өлкәсендәге корылмалар һәм төзелеш эшләре | |
| Махсуслаштырылган төзелеш эшләре | |